**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Түйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Түйкә авылы №37-16 «15» июль 2016 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Советының 2013 елның 08 февралендәге 51 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә үз теләге белән эштән азат ителүгә (инвалидлыкка) һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү түләү турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

"Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законның 2.1 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында" 2015 елның 30 декабрендәге 446-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясы нигезендә федерациянең", прокурорның 2016 елның 15 февралендәге 02-08-02/389-20-2016 номерлы протестын исәпкә алып,

Түйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Советының 2013 елның 08 февралендәге 51 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында " карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә үз теләге белән эштән азат ителүгә (инвалидлыкка) һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү түләү турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2015 елның 30 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.Р. Закирова